# Её творчество во благо людей

Есть люди, с которыми приятно общаться. От них заряжаешься энергией оптимизма. И проблемы уже не кажутся столь не решаемыми. К таким, безусловно, относится Резеда Валиева. В один из октябрьских дней она нам — ее читателям и почитателям подарила несколько часов праздника общения с ней.

А было это в Бугуруслане, в Тукаевском Доме культуры, куда она приехала с теми, кто ее пригласил в наши края. Инициатором визита известной поэтессы Татарстана в Оренбуржье стала Асекеевская татарская автономия и лично Зайтуна Валишина.

Отрадно было узнать, что предки Резеды Валиевой по одной из ветвей родословной из наших краев.

Встреча радушная, с улыбками на лицах. Председатель татарского общественного центра Бугуруслана , Генеральный директор ЗАО «Телекомпания «Новый век- Бугуруслан» Хамзя Газизов преподнес цветы поэтессе и от имени татар города горячо приветствовал ее.

Несмотря на то, что активисты центра ездили накануне на экскурсию в Казань и устали, многие пришли на встречу с поэтессой. Разговоры по душам за чашкой чая, рассказы о непростой судьбе и творческих планах...

Резеда-апа просто покорила все нас своим жизнелюбием, оптимизмом, умением дарить тепло и радость окружающим. И снова и снова мы просили ее исполнить свои произведения, которые, к слову, она помнит наизусть. Но особенно понравились всем стихи про Бабушку. В них прекрасное сочетание юмора и фольклора...

## Әбине жәлләп кенә...

*Ерак түгел арабыз,*
*Әбиләргә барабыз.*
*Барабыз җәйләп кенә*
*Әбине жәлләп кенә.*
*Җиләкләр пешкән чакта,*
*Яңа бал төшкән чакта...*

*Әбиеңә куаныч,*
*Карт көнендә юаныч*
*Булырсың,- дип әйтәләр,*
*Мине дә иярләләр.*

*"Жигули"лар ак кына,*
*Утырып җәйлап кына,*
*Китәбез инде менә,*
*Әбине жәлләп кенә*
*Җиләкләр пешкән чакта,*
*Яңа бал төшкән чакта...*

*Безнең килгәнне күреп,*
*Әби чыга йөгереп,*
*Бер елмая, бер көлә,*
*Орчыктай бөтерелә.*

*Әле каймагын китерә,*
*Әле тавыгын куя.*
*Тавык кына коткармагач,*
*Соңгы сарыгын суя...*
*Сарык ите тиз пешә,*
*Бәлешкә дә килешә.*

*Ашыйбыз тәмләп кенә,*
*Әбине жәллеп кенә.*

*Шундый матур җәйләрдә*
*Ятабыз әбиләрдә,*
*Гөлбакчалар эчендә,*
*Иртәсен дә, кичен дә,*
*Ит ашап, каймак эчеп,*
*Түзәсең моңа ничек?*

*Түзәбез индә менә,*
*Әбине жәлләп кенә*

*Үтә индә җәйләр дә,*
*Кайтабыз әбиләрдән.*
*Күңеле булсын өчен,*
*Алабыз кайсыберсен:*
*Каклаган казын, кагын,*
*Чәк-чәген, бавырсагын,*
*Балын, маен, тавыгын,*
*Оекбашын, мамыгын.*

*Өйдә әби бүләкне,*
*Ниләр генә куймады.*
*Сыерын да бирә иде,*
*Машинага сыймады.*

*Ала идек шул менә,*
*Әбине жәлләп кенә...*

***(Из сборника Резеды ВАЛИЕВОЙ)***

Книги для детей и взрослых, автографы. Хозяева долго не хотели отпускать поэтессу. Она обещала вернуться внаши края в скором времени и порадовать новыми произведениями.

**Ф.ФАТТАХОВ.**

**На снимке:** на память с известной поэтессой.



ГОСТИ ИЗ ТАТАРСТАНА



# Туган як шагыйрәсе

*Туган ягым минем*
*бигрәк матур*
*Кин колачлы аның кырлары*
*Урманында төрле*
*кошлар сайрый*
*Көмеш төсле аккан сулары.*

Кем икән соң бу ихлас сүзләрнең авторы? Бу Әсәкәй авылында яшәүче Нурзимә ханым Гизетдинова.

Аның нечкә шигъри җаны Карамалы авылының 8 балалы татар йортында ата-ананың җылы кочагында төпчек бала булып назланып тәрбияләнгән.

Нурзимә ханым инде күптән үзе дә ике бала анасы, 3 оныкчыгының яраткан әбкәе.

Бу тормышның кадерен белүче ханым донья мәшәкәтләренән арынып төннәр утырып күңел түреннән ак кәгазгә матур шигъри юллар тезәргә каян илһам һәм көч ала икән? Йорт-жире тулы мал-туар, бакча эшләре, өй мәшәкәтләре. Әлбәттә донья эшләрен алар кулга-кул тотынып ире Сәет белән алып баралар 43 ел дәвамендә.

Сәет Баширович хатынына тиң бик уңган-булган үзе электрик, механизатор, ә хәзер булдыклы эшкуар ир. Бу пар татар гаиләсенең өлгесе дип әйтерлек. Ата-анага хөрмәт, күршеләргә карата булган изгелек, татулык, тормышка карата аек акыл, балаларга дөрес тәрбия бирү, болар барысы да Нурзимә ханымның шигырьләрендә дә чагылган.

Нурзимәгә татар халкының уңганлык, яхшы күңеллелек, изгелек сыйфатларын ата-анасының дөрес тәрбиясе сеңдергән әлбәттә.

Менә бит аның шигъри юллары иң кадерле кешеләрәнә карата:

*Таң калабыз, әнкәй*
*синең яхшылыкка*
*Сокланабыз синең*
*сабырлыкка...*

*Син изге җан әткәй, син әүлия*
*Безнең яшәү намус токасы...*

Менә шундый үрнәк гаилә бишегендә чын татар кызы булып тәрбияләнгән безнең Әсәкәй шагыйрәсе. Менә аның бер шигыре "Күршеләр"

*Иртән торсаң күрше кирәк*
*Исәнмесез! — диеп дәшәргә*
*Хәл — әхвәлләр сорап,*
*сез ничек? — дип*
*Авыр булса, ярдәм итәргә.*

*Шатлык булса, бергә сөенәсең*
*Кайгыларны кирәк —*
*читкә этәргә*
*Нәрсә генә дисәң —*
*күрше кирәк*
*Тормышларны бергә күтәргә.*

*Әкрен генә искән, җилләр коя*
*Алма агачының чәчәген*
*Табыннарга утырсаң тәмле була*
*Күршеләр белән*
*эчкән чәйләрең.*

*Үзең яхшы булсаң күршеләр дә*
*Әйбәт булыйм — диеп тырыша*
*Күрше хакы — Алла хакы диеп*
*Эшең булса, кереп булыша.*

*Мин телимен, күршеләргә*
*Исәнлек — саулык тынычлык*
*Озын гөмер, бәхет,*
*сөенеч белән*
*Өстәлеп торсын шатлык.*

Алдагы чыгарылыш газета битләрендә без аның шигырьләре белән сезне тагы да таныштырырбыз.

**З.ВАЛИШИНА.**

МӘДӘНИЯТ УЧАГЫ

# Уйла газиз милләтеңне

Узган гасырның 20-нче елларында Богырыслан шәһәрендә татарлар күмәкләшеп яшәгән җирдә китапханә эшләп китә. Аны җитәкләгән, анда эшләгән кешеләрне чын мәгънәсендә энтузиастлар диярге була. Халык (аеруча яшьләр) атылалар янына.Ник, дисезме? Бик кирәк, эчтәлекле, мәгънәле, кызыклы чаралар үткәрелгән бу чорда мәдәният учакларында. Беренче китапханәче дип без беләбез Сафин Ханифне.

Татар булуларына горурланып, милли, гореф гадәтләрне өйрәнеп,аларны халыкка җиткерү бу төп максат мәдәният өлкәсендә эшләгән хезмәткәрләрнең. Ул вакытта китапханә дә, клубта бер бинада урнашкан була. Гөрләп торган мәдәният учагы.

Алтынчы санлы китапханә Богырысланда милли китапханә дип исәпләнә. Тулысынча милли китапханә була алмаса да (чөнки милли өлеше китапның зур түгел), безнең эшнең төп юнәлеше — милли эшләр. Олылар , балалар, урта яшьтәге укучыларның һәрберсе күңелгә ятышлысын табалар — китап дисеңме, гәҗитме, журналмы.

Татар иҗтимагый үзәге тарафыннан гәҗит-журналлар, китаплар юнәлтелә.

Укучы балалар бигрәк кызыксыналар этнографик мәгълүматләр белән. Әти-бабайлар рәхәтләнеп үзләренә кирәккән гәҗитжурналлар укыйлар (алар бездә һәркемнең куңеленә хуш килерлек күп төрле). Хәтта сабыйлар гада (балалар бакчасына йөрүчеләр) кирәкле китап-журналлар бар.

Күп еллар эшләп килгән татар якшәмбе мәктәбе укучыларына, укытучыларга безнең китапханә зур ярдәмче. Бергәләшеп, күп кенә чаралар уздырабыз: туган тел бәйрәме, науруз, гөреф гадәтләрне өйрәнү кичәләре, бөек татар язучыларына багышланган чаралар уздырабыз.

Безнең китапханә клуб бинасында урнашкан. Аның уңай яклары бик куп: берләшеп эшлибез. Бугенге көндә мәдәният йортын җитәкли бик сәләтле Румия Халит кызы Хәмитова. Аның җитәкчелегендә бик уңган булган кызлар егетләр эшли.

Эшебез бер: халыкка милли тәрбия бирү, җырларын-моңнарын, биюләрен, бәйрәмнәрен, гөреф гадәтләрен күңелдә саклап, киләчәк буынга тапшырырга.

**Гөлфия ЛАТЫЙПОВА,**
**китапханәче.**
**Богырыслан шәһәре.**